**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы  Дурт-Мунча авыл җирлеге Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены карары**

14.11.2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елда Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын, белем бирүнең көндезге формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- Елга аръягы урамы буенча агачларны кисү;
- христиан зиратында агачларны кисү;
- зиратка мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру;
- территорияне чабу;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү;
- янгынга каршы инвентарь сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Дурт-Мунча авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе ________________ Р.Т.Ситдиков
(имза) (имза расшифровкасы)